ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**2017 елның 03 февраленнән**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 173**

2017 - 2019 елларга Зеленодольск муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча Региональ программаны гамәлгә ашыруның Кыска сроклы планын раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексын, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2017 - 2019 елларга Зеленодольск муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планын №1, № 2, №2/1,№2/2, №2,3, №3/1, №3/2, №3/3, №4/1, №4/2, №4/3 кушымталары нигезендә расларга.
2. ЗМР Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге башлыгы А.Н. Коршуновка әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Житәкче А.Х. Сәхибуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2017 елның 03 февралендәге
173 номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1146 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча Региональ программаны гамәлгә ашыруның Кыска сроклы планы

## I. Гомуми нигезләмә

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 июнендәге 1146 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планы (алга таба – Кыска сроклы план, Региональ программа) Россия Федерациясе Торак кодексы, «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итү фонды турында» 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - Федераль закон), «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба - Татарстан Республикасы Законы) нигезендә, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау срокларын төгәлләштерү, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр төрләрен төгәлләштерү, капиталь ремонт үткәрүгә дәүләт ярдәме төрләрен һәм күләмен билгеләү максатларында эшләнгән.

## II. Кыска сроклы планның төп максатлары һәм бурычлары

Кыска сроклы планның төп максатлары булып түбәндәгеләр тора:
Зеленодольск муниципаль районында торак фондын саклау, торгызу һәм аның сыйфатын күтәрү;
гражданнарның имин һәм уңайлы яшәү шартларын булдыру, дәүләт ярдәме, күп фатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлауга муниципаль ярдәм күрсәтү.

Кыска сроклы планның төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:
халык белән актив агитация-аңлату эшләре алып бару;
Кыска сроклы планны башкаручыларны сайлап алуның үтә күренмәле һәм ачык процедураларын эшләү һәм үтәү;

капиталь ремонт үткәргәндә, озакка чыдам материаллар һәм ресурслар саклый торган технологияләр кулланып, нәтиҗәле техник чишелешләрдән һәм комплекслылыктан файдалану.

2017-2019 елларга кыска сроклы планны гамәлгә ашыру срогы.

Краткосроклы планны гамәлгә ашыру яшәү өчен имин һәм уңайлы шартлар тәэмин итәргә тиеш

2017 ел - 33 күпфатирлы йорттларда , гомуми мәйданы 127 000,61 кв.метр булган, 5761 граждан;

2018 елда - 28 күпфатирлы йорттларда, гомуми мәйданы 100 864,27 кв.метр булган, 4603 граждан;

2019 ел - 32 күпфатирлы йорттларда гомуми мәйданы 89538,75 булган,4294 граждан;

Әлеге кыска сроклы планны үтәүнең планлаштырылган күрсәткечләре 2/1 нче, 2/2 нче, 2/3 нче кушымтада күрсәтелгән.

## III. Зеленодольск муниципаль районының кыска сроклы планны үтәүдә катнашучылар торак пунктлары исемлеге

Кыска сроклы планны үтәүдә катнашучы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре исемлеге, мондый торак пунктлар территориясендә Федераль законның 14 статьясында каралган финанс ярдәме күрсәтү шартлары үтәлүен исәпкә алып, төзелгән;

Кыска сроклы планны гамәлгә ашыруда Зеленодольск муниципаль районының түбәндәге торак пунктлары катнаша: Зеленодольск шәһәре, Карамалы Тау штп, Васильево штп, Әйшә, Бело-Безводное, Осиново, Большие Ключи, Раифа, Олы Җәке авыллары.

## IV. 2017 - 2019 елларда
## Зеленодольск муниципаль районында күп фатирлы йортларга капиталь ремонт үткәрү күләме

| № т/б | Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр исемлеге | Үлчәү берәмлеге | Эш күләме | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2017 | 2018 | 2019 |
| 1. | Түбә ремонтлау | кв. метр | 31 503,75 | 25 679,95 | 17 534,49 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 2. | Торак биналарда булган электр, җылылык, газ, су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау яки алыштыру, шул исәптән торак биналарда булган җылыту элементларын, шулай ук йорт эчендәге инженерлык системаларында урнашкан механик, электр, санитар-техник җиһазларны ремонтлау яки алыштыру, шул исәптән: | пог.метр | 39 854,93 | 46 764,31 | 48 913,17 |
| 3. | электр белән тәэмин итү | пог.метр | 6 456,90 | 5 541,49 | 10 874,07 |
| 4. | җылылык белән тәэмин итү | пог.метр | 19 660 | 21 728,23 | 26 038,07 |
| 5. | су белән тәэмин итү | пог.метр | 11 398,49 | 10 597,35 | 5 618,14 |
| 6. | су чыгару | пог.метр | 8 796,44 | 8 897,24 | 6 382,89 |
| 7. | Файдалану өчен яраксыз дип табылган лифт җиһазларын алыштыру | данә | 6 | 10 | 8 |
| 8. | Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә караган подвалларны ремонтлау | кв. метр | 6 104,3 | 5 651,40 | 8 982,19 |
| 9. | Фасадны җылыту һәм ремонтлау | кв. метр | 28 722 | 27 606,4 | 41 145,78 |
| 10. | Күпфатирлы йортның фундаментын ремонтлау | куб. метр | 0 | 0 | 264 |
| 11. | Күпфатирлы йортларны техник инвентаризацияләү буенча эшләр үткәрү һәм техник паспортлар әзерләү | данә | 20 | 26 | 0 |
| 12. | Күпфатирлы йортта подъездларны ремонтлау | кв. метр | 9 136,9 | 6 960,49 | 9 886 |
| 13. | Төзелеш контролен гамәлгә ашыру | данә | 33 | 28 | 32 |
| 14. | Проект документларына дәүләт экспертизасын эшләү һәм үткәрү | данә | 33 | 28 | 32 |

Күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясау күләмнәре «2016-2018 елларга Зеленодольск муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлауның төбәк программасын гамәлгә ашыруның кыска сроклы планына кертелгән ремонт

төрләре буенча күпфатирлы йортлар реестры 3/1 нче, 3/2 нче, 3/3 нче кушымталарында китерелде.

## V. Ресурслар белән тәэмин итү

Кыска сроклы планны финанслау чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджеты һәм (яки) җирле бюджет акчалары, торак мөлкәтчеләре ширкәтләре, торак комплексы, торак-төзелеш кооперативлары ((алга таба – ТМШ, ТК, ТТК ) яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативлары яки күпфатирлы йорттагы бина милекчеләренең акчалары тора.

Кыска сроклы план чараларын финанслауның гомуми күләме 2017 елда 247 891 152,34 сум тәшкил итәчәк, шул исәптән акчалар:

Татарстан Республикасы бюджетыннан - 70 895 090 сум;

җирле бюджетларныкы-48 927 000 сум;

ТМШ,ТК, ТТК яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативлары яки күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре әгъзаларыныкы - 128 069 062,34 сум.

2018 елда 233 497 173,10 сум тәшкил итәчәк, шул исәптән акчалар:

Татарстан Республикасы бюджетыкы - 63 125 957 сум;

җирле бюджетларныкы-48 927 000 сум;

торак милекчеләре ширкәте, торак кооперативы, торак-төзү кооперативы, яисә башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативлары яки күпфатирлы йорттагы биналарның милекчеләре ширкәте әгъзаларыныкы - 121 444 216,10 сум.

2019 елда 236 310 877,73 сум тәшкил итәчәк, шул исәптән акчалар:

Татарстан Республикасы бюджетыныкы - 61 889 230 сум;

җирле бюджетныкы - 48 927 000 сум;

торак милекчеләре ширкәте, торак кооперативы, торак-төзү кооперативы, яисә башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативлары яки күпфатирлы йорттагы биналарның милекчеләре ширкәте әгъзаларыныкы - 125 494 647,73 сум;

2017-2019 елларда
күп фатирлы йортларны капиталь ремонтлау өчен финанс чаралары күләме

| № т/б | Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Суммасы,млн. сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 2017 | 2018 | 2019 |
| 1. | Түбә ремонтлау | 93,6 | 69,06 | 57,01 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2. | Торак биналарда булган электр, җылылык, газ, су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау яки алыштыру, шул исәптән торак биналарда булган җылыту элементларын, шулай ук йорт эчендәге инженерлык системаларында урнашкан механик, электр, санитар-техник җиһазларны ремонтлау яки алыштыру, шул исәптән: | 103,07 | 107,3 | 106,9 |
| 2.1. | электр белән тәэмин итү | 9,7 | 9,3 | 12,7 |
| 2.2. | җылылык белән тәэмин итү | 53,4 | 56,8 | 71,6 |
| 2.3. | су белән тәэмин итү | 20,2 | 21,03 | 8,7 |
| 2.4. | су чыгару | 19,7 | 20,1 | 13,7 |
| 3. | Файдалану өчен яраксыз дип табылган лифт җиһазларын алыштыру | 10,5 | 17,5 | 13,7 |
| 4. | Күпфатирлы йортларда уртак мөлкәткә караган подвал бүлмәләрен ремонтлау | 4,6 | 4,5 | 6,3 |
| 5. | Фасадны җылыту һәм ремонтлау | 21,6 | 21,7 | 36,3 |
| 6. | Күпфатирлы йортның фундаментын ремонтлау | 0 | 0 | 0,5 |
| 7. | Күпфатирлы йортларны техник инвентаризацияләү буенча эшләр үткәрү һәм техник паспортлар әзерләү | 0,9 | 0,6 | 0 |
| 8. | Күпфатирлы йортта подъездларны ремонтлау | 3,8 | 3,6 | 6,01 |
| 9. | Проект документларына дәүләт экспертизасын эшләү һәм үткәрү | 7,1 | 6,7 | 6,6 |
| 10. | Төзелеш контролен гамәлгә ашыру | 2,3 | 2,2 | 2,2 |
| | Барлыгы | 247,8 | 233,4 | 236,3 |

Кыска сроклы планга капиталь ремонт үткәрүнең бәясен күрсәтеп, күпфатирлы йортлар исемлеге 4/1 нче, 4/2, нче ,4/3 нче кушымтада китерелгән.

## VI. Капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең иң чик бәясе

2017-2019 елларга күпфатирлы йортларда биналарның гомуми мәйданының 1 кв. метрына исәпләгәндә хезмәтләрнең һәм (яки) капиталь ремонт эшләренең чик бәясе 14 мең сум тәшкил итә.

Шул ук вакытта хәзерге кыска сроклы планга кертелгән күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау буенча хезмәтләрнең һәм (яки) эшләрнең чик бәясенең эш төрләре буенча күләме, Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы боерыгы (алга таба – Министрлык) белән раслана.

Әлеге бүлектә каралган хезмәтләрнең һәм (яисә) капиталь ремонт эшләренең иң чик бәясен арттыру, шулай ук кыска сроклы план белән каралмаган хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр өчен түләү, күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре акчалары исәбеннән башкарыла, ул капиталь ремонтка кертемнең минималь күләменнән тыш капиталь ремонт өчен кертем рәвешендә түләнә.

## VII. Кыска сроклы планны тормышка ашыру механизмы

Әлеге кыска сроклы планны гамәлгә ашыру Министрлык, коммерцияле булмаган «Татарстан Республикасы торак-коммуналь хуҗалыгы Фонды» оешмасы (алга таба – региональ оператор), Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, ТМШ, ТК, ТТК, идарә оешмалары (алга таба – УО), биналарның милекчеләре, подрядчы оешмалар (алга таба – кыска сроклы планны үтәүчеләр) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Министрлык:

Кыска сроклы планны үтәүчеләр белән үзара хезмәттәшлекне, Кыска сроклы план чараларын гамәлгә ашырганда аларның эшчәнлеген координацияләүне һәм контрольдә тотуны оештыра;

Региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы (еллык) планнарын карый һәм муниципаль берәмлекләр тарафыннан финанс ярдәме күрсәтү шартларының үтәлешен тикшерә;

күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны үз вакытында үткәрүне тәэмин итү максатларында Региональ оператор белән хезмәттәшлек итә;

Кыска сроклы планны гамәлгә ашыруны мониторинглауны һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан тапшырыла торган хисаплылыкны анализлау нигезендә финанс ярдәме күрсәтү шартларын үтәүне гамәлгә ашыра;

үзенең сайтында Кыска сроклы планга кергән күпфатирлы йортларның исемлеген урнаштыра;

капиталь ремонт үткәрү өчен, шул исәптән тиешле тәртипне раслау юлы белән дә, подрядчы оешмаларны сайлап алу процедурасында катнаша;

үз компетенциясе кысаларында Кыска сроклы план чараларын гамәлгә ашыруны контрольдә тотуны оештыра.

Региональ оператор:

дефектлы ведомстволар әзерләү, шулай ук түләү документларын формалаштыру һәм капиталь ремонт өчен биналарның милекчеләреннән Региональ оператор хисабына взнослар керүне тәэмин итү буенча ИО белән килешүләр төзи;

проект документациясен әзерләүгә, техник заказчы функцияләрен гамәлгә ашыруга, төзелеш контролен гамәлгә ашыруга шартнамәләр, шулай ук күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча эшләрне һәм (яки) хезмәтләрне башкаруга подряд шартнамәләре , шул исәптән күрсәтелгән хезмәтләргә һәм (яки) башкарылган эшләргә гарантия срогын билгеләүне һәм күрсәтелгән хезмәтләрне һәм (яисә) башкарылган эшләрне кабул итү турындагы тиешле актка кул куйганнан соң биш ел дәвамында башкарылуын күздә тоткан, шулай ук ачыкланган җитешсезлекләрне үз хисабына һәм үз көчләре белән бетерү буенча подрядчы оешмаларның йөкләмәләрен төзи;

үзенең рәсми сайтында күпфатирлы йортта биналарның милекчеләренең һәм региональ операторның Торак кодексы, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары таләпләрен үтәү белән бәйле барлыкка килгән хокуклары һәм бурычлары турында, капиталь ремонт үткәрүне оештыру турында мәгълүмат, шулай ук исемлеге Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2015 елның 11 ноябрендәге 803/пр номерлы боерыгы белән билгеләнгән башка белешмәләр урнаштыра;

законнарда билгеләнгән тәртиптә күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау өчен, подрядчы оешмаларны сайлап алуны гамәлгә ашыра;

күпфатирлы йортта уртак мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләрне һәм (яисә) эшләрне финанслауны, проект документациясен әзерләү, законнар таләпләре нигезендә төзелеш контроле буенча, Кыска сроклы план белән каралган күләмдә һәм срокларда гамәлгә ашыра;

төзелеш контролен гамәлгә ашыручы оешма, биналар милекчеләре вәкиле тарафыннан идарәче оешма, муниципаль берәмлек, Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе, төзелеш контролен гамәлгә ашыручы оешма белән килештерелгән КС-3, КС-2 формалары нигезендә башкарылган эшләргә подряд оешмалары өчен түләүне башкара;

күпфатирлы йортта биналарның һәр милекчесе буенча акча керүне исәпкә алуны гамәлгә ашыра;

Министрлыкка кыска сроклы планны гамәлгә ашыру кысаларында соратылган документларны һәм белешмәләрне тапшыра;

законнарда каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе:

капиталь ремонт эшләрен башкаруның дефектлы ведомостьларын һәм күпфатирлы йортларга капиталь ремонт үткәрү буенча муниципаль адреслы программаларны, программаларны тормышка ашыруның Кыска сроклы планнарын килештерә;

күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау өчен подрядчы оешмаларны сайлап алу процедурасында катнаша, капиталь ремонт

үткәрү өчен квалификацияле һәм намуслы подрядчы оешмаларны җәлеп итүне контрольдә тота;

күпфатирлы йортка капиталь ремонт ясауның үз вакытында һәм сыйфатлы башкарылуын контрольдә тота;

башкарылган эшләр һәм (яисә) хезмәт күрсәтүләр актларын килештерә;

капиталь ремонт тәмамланган объектны файдалануга кабул итүдә катнаша;

подряд килешүләре реестрын алып бара;

капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулын сайлау турында милекчеләрнең җыелышларының беркетмәләрен исәпкә алып бара;

соратып алына торган документларны һәм белешмәләрне Кыска сроклы планны гамәлгә ашыру кысаларында Министрлыкка һәм башка Кыска сроклы планны башкаручыларга тапшыра.

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары:

Региональ программаны тормышка ашыруның кыска сроклы (еллык) муниципаль планнарын формалаштыралар һәм Министрлыкка җибәрәләр;

Министрлыкка муниципаль берәмлек тарафыннан финанс ярдәме күрсәтү шартларының үтәлешен раслаучы норматив хокукый актларның күчермәләрен һәм башка документлар тапшыралар;

капиталь ремонт үткәрү өчен подрядчы оешмаларны сайлау процедурасында катнашалар;

җирле бюджет акчаларын Федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм торак законнары нигезендә әлеге Кыска сроклы планда билгеләнгән күләмдә капиталь ремонт эшләрен финанслашуга күчерәләр;

Региональ оператор белән килешү (шартнамә) нигезендә күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча эшләрнең техник заказчысы функцияләрен гамәлгә ашыралар;

башкарылган эшләр актларын, капиталь ремонт эшләрен кабул итү актларын, күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау өчен расланган чыгымнар сметасында каралмаган акчалардан тыш, шулай ук ул арткан очракта гына, килештерәләр;

күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча эшләр башкаруга бүлеп бирелә торган акчаларның максатчан кулланылышын контрольдә тоталар;

Министрлык билгеләгән тәртиптә тиешле муниципаль берәмлек буенча Кыска сроклы планны (шул исәптән күпфатирлы йортларда торак һәм торак булмаган биналар мәйданнары буенча мәгълүматларны) гамәлгә ашыру максатларында мәгълүматлар базасын барлыкка китерәләр һәм актуаль хәлдә тоталар;

Министрлыкка һәм Кыска сроклы планны башка башкаручыларына Фондка хисаплар формалаштыру өчен кирәкле документларны һәм белешмәләрне тапшыралар.

Торак хуҗалары ширкәте, Торак-төзелеш кооперативы, Торак комлексы, Идарә итү оешмалары:

тикшерү актларын, капиталь ремонт эшләре күләменә дефект исемлекләрен, башкарылган эшләр актларын һәм (яки) хезмәтләр күрсәтүне килештерәләр;

региональ оператор белән түләү документларын формалаштыруга һәм ай саен түләүне тәэмин итүгә һәм региональ оператор счетына капиталь ремонт кертемнәре буенча милекчеләрнең түләүләре керүгә шартнамәләр (килешүләр) төзиләр;

проект документларын әзерләүне тәэмин итәләр;

Министрлык тарафыннан расланган Тәртип нигезендә сайлап алуның оештыручысы булып торалар;

капиталь ремонт үткәрү өчен подрядчы оешмаларны сайлау процедурасында катнашалар;

биналарның милекчеләренә капиталь ремонт башлану вакыты, кирәкле исемлек һәм хезмәтләр һәм (яки) эшләр күләме, аларның бәясе, күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне капиталь ремонтлауны финанслау тәртибе һәм чыганаклары турында тәкъдимнәр һәм Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә, капиталь ремонт үткәрүгә бәйле башка тәкъдимнәр тапшыралар;

күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау мәсьәләләре буенча милекчеләр җыелышларын оештыралар;

капиталь ремонт объектларына рөхсәтне гамәлгә ашыралар;

күп фатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонтлауны үз вакытында һәм сыйфатлы башкаруны контрольдә тотуда, шулай ук аларны капиталь ремонт тәмамланган объектларны тикшерү һәм файдалануга тапшыру актларына кул кую хокукы белән файдалануга алуда катнашалар.

күпфатирлы йортны һәм аңа керүче инженер системаларын авариясез эксплуатацияләүнең билгеләнгән гарантияле срогыннан ким булмаган вакытка күпфатирлы йортны капиталь ремонтлау буенча кимчелекле ведомостьлар, проект-смета һәм башкарма документларны саклыйлар.

Бина милекчеләре:

тикшерү актларын, капиталь ремонт эшләре күләменә карата дефектлы ведомостьларны килештерәләр;

күп фатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлауны үз вакытында һәм сыйфатлы башкаруны контрольдә тотуда, шулай ук аларны капиталь ремонт тәмамланган объектларны тикшерү һәм файдалануга тапшыру актларына кул кую хокукы белән файдалануга алуда катнашалар.

Подрядчы оешмалар:

күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча Кыска сроклы план һәм подряд килешүе белән билгеләнгән срок эчендә эшләрне башкаруны тәэмин итәләр;

КС-2, КС-3 формалары буенча башкарылган эшләр актларын төзиләр;

күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча эшләрне башкарганда төзелеш контролен гамәлгә ашыралар;

күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча эшләрне сыйфатлы һәм үз вакытында башкарган өчен җавап тоталар;

объектны файдалануга тапшыруны тәэмин итәләр;

подряд килешүендә каралган башка эшләрне башкаралар.

Техник заказчы функцияләрен башкаручы оешмалар:

проект документларын, шул исәптән сметаны әзерләүне һәм раслауны гамәлгә ашыралар;

күпфатирлы йортларда капиталь ремонт үткәрү вакытында төзелеш контролен гамәлгә ашыралар;

башкарылган эшләрне кабул итүдә катнашалар, башкарылган эшләр актларын килештерәләр;

объектны кулланышка кабул итүдә катнашалар, объектны кабул итү актын килештерәләр;

күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча эшләрне сыйфатлы һәм үз вакытында башкарган өчен җавап тоталар;

проект оешмасыннан проект-смета документларын кабул итәләр;

күпфатирлы йортта күрсәтелгән хезмәтләрне һәм (яки) гомуми мөлкәтне капиталь төзекләндерү буенча башкарылган эшләрне кабул итү актына кул куйганнан соң, 10 көн эчендә, әлеге күпфатирлы йорт белән идарә итүче затка күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь төзекләндерү турындагы документларның күчермәләрен (шул исәптән, проект, смета документлары, хезмәтләр күрсәтү һәм (яки) капиталь төзекләндерү буенча эшләр башкару турындагы шартнамәләрнең күчермәләрен) һәм капиталь төзекләндерү үткәрүгә бәйле башка документларны, финанс документларыннан тыш;

законнарда каралган техник заказчының башка функцияләрен гамәлгә ашыралар.

«Татмедиа» ААҖ филиалы - «Зеленодольская правда», «Наш Зеленый Дол» » газеталары массакүләм мәгълүмат чараларында Кыска сроклы план чараларын гамәлгә ашыру барышын даими яктыртып тора.

Кыска сроклы планны планлаштыру, үтәү, контрольдә тоту һәм мониторинглау «Торак фонды мониторингы»бердәм мәгълүмат продуктында тормышка ашырыла.